**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“4” декабрь 2025 ел. № 2

«Җәмәгать хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Яңа Шимбер торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер авылы территориясендә 2026 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Яңа Шимбер авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге формада укучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, сиксән яшьтән өлкәнрәк гражданнар, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашучы) затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Торак пункт территориясен төзекләндерү (Яңа Шимбер бистәсендә үлән чаптыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү ); (Яңа Шимбер авылы балалар мәйданчыгын төзекләндерү (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү));

2) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яңа Шимбер авылының урам юлларын кардан чистарту (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

Аерым мәсьәләләр буенча экономияләнгән очракта Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлегенең Яңа Шимбер авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Түбән Көек авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Яңа Шимбер авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Галиәхмәтов Д.М.